**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

**№ 6** **«19» октябрь 2020 ел**

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»

карарының (2018 елның 15 ноябрендәге 95 номерлы үзгәрешләр белән) 1 өлешендәге 3 абзацын бәян итәргә:

1.1. «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

1.2. «Знче кушымтаны «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләме» яңа редакциядә бәян итәргә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе А.Б. Кәримов

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
Советының 2020 елның 19 октябрендәге
6 номерлы карарына

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының
айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаларның атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
| --- | --- |
| Башлык | 15759,00 |